ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.12.2022 Баулы шәһәре № 259

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 5 сентябрендәге 394 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 августындагы 865 номерлы һәм 2022 елның 15 сентябрендәге 1007 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган су объектларында гражданнарның оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль учреждениеләре һәм шәһәр округлары бюджетларының Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарын билгеләү методикасын раслау хакында» карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген

характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 5 сентябрендәге 394 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 гыйнварындагы 14 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 209 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә (карарга 1 нче кушымта):

II «Хезмәткәрләрнең окладлары (вазыйфаи окладлары, тариф ставкалары) күләмнәре» бүлегендә 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2.1. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1 нче таблицада китерелгән.

Таблица 1

| № п/п | Вазифа атамасы | Вазифаи окллад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 19 862,00 |
| 2. | Учреждение оператив дежурные | 15 279,00»; |

III «Компенсация характерындагы түләүләрне билгеләү шартлары, күләмнәре һәм тәртибе» бүлегендә:

3.5. пункт үз көчен югалткан дип санарга;

3.6. пунктның 1) һәм 2) пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) төнлә (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) нормаль булмаган шартларда эшләгән өчен айлык өстәмәләр - төнлә эшләгән һәр сәгатьтә хезмәт хакының 35 процентыннан һәм планлаштырыла торган елга җитештерү календаре нигезендә төнлә эшләү сәгатьләре санынннан чыгып;

2) эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен айлык өстәмәләр - Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән күләмнән һәм тиешле елга җитештерү календаре нигезендә эш көне булмаган бәйрәм көннәре санынннан чыгып;»;

3.9. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык өстәмәләр - елына 0,3 вазифаи оклад күләмендә.

Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен күрсәтелгән айлык өстәмәләр, законнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, дәүләт серенә даими нигездә рөхсәте булган хезмәткәрләргә түләнә.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров